МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

__14.02.2018_____ г. Казань № _116од______

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре адресы буенча урнашкан, Пушкин, Держинский, Лобачевский урамнары һәм Казан Федераль Университеты корпуслары чигендәге Ленин бакчасының өске һәм аскы террасаларын тоташтыра торган «Ленин бакчасындагы баскыч, 1924 ел», архитектор Ф.П.Гаврилов ачыкланган мәдәни мирас объектын Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) бердәм дәүләт реестрына җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты сыйфатында истәлекле урын төре буларак кертү һәм сак предметын, чикләрен һәм мәдәни мирас объекты территорияләреннән файдалану режимын раслау турында

“Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) турында”гы 2002 елның 25 июнендә кабул ителгән 73-ФЗ номерлы законы, “Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында”гы 2005 елның 1 апрелендә кабул ителгән 60-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Министрлар Кабинетының 2016 елның 10 нчы июнендә кабул ителгән “Төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектын яки җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) бердәм дәүләт реестрына төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты сыйфатында кертү турында карар кабул итү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында”гы 393 нче карары, 2015-нче

елның 30-нчы сентябрендәге дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының уңай нәтиҗәсе нигезендә **боерам:**

1. Татарстан Республикасы, Казан шәһәре адресы буенча урнашкан, Пушкин, Держинский, Лобачевский урамнары һәм Казан Федераль Университеты корпуслары чигендә урнашкан Ленин бакчасының югары һәм түбән террасаларын тоташтыра торган «Ленин бакчасындагы баскыч, 1924 ел», архитектор Ф.П.Гаврилов ачыкланган мәдәни мирас объектын Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) бердәм дәүләт реестрына Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Ленин бакчасы адресы буенча урнашкан “Ленин бакчасындагы баскыч” 1924 ел, архитектор Ф.П.Гаврилов төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объекты сыйфатында кертергә һәм мәдәни мирас объекты төре – архитектура һәм шәһәр төзелеше һәйкәле итеп билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Ленин бакчасы адресы буенча урнашкан “Ленин бакчасындагы баскыч” 1924 ел, архитектор Ф.П.Гаврилов төбәк дәрәҗәсендәге мәдәни мирас объектының сак предметын расларга (1нче кушымта).

3. Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Ленин бакчасы адресы буенча урнашкан “Ленин бакчасындагы баскыч” 1924 ел, архитектор Ф.П.Гаврилов төбәк дәрәҗәсендәге мәдәни мирас объекты территориясенең чикләрен расларга (2нче кушымта).

4. Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Ленин бакчасы адресы буенча урнашкан “Ленин бакчасындагы баскыч” 1924 ел, архитектор Ф.П.Гаврилов төбәк дәрәҗәсендәге мәдәни мирас объекты территориясеннән файдалану режимын расларга.

5. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Министр А.М. Сибагатуллин

Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгының
2018нче елның
«________»__________
№ ___боерыгына
1- нче кушымта

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Ленин бакчасы адресы буенча урнашкан “Ленин бакчасындагы баскыч” 1924 ел, архитектор Ф.П.Гаврилов төбәк дәрәҗәсендәге мәдәни мирас объектының **сак предметы**

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Ленин бакчасы адресы буенча урнашкан “Ленин бакчасындагы баскыч” 1924 ел, архитектор Ф.П.Гаврилов төбәк дәрәҗәсендәге мәдәни мирас объектының сак предметы булып түбәндәгеләр тора:

- скульптур композициянең урнашкан урыны, тарихи парк структурасында шәһәр төзелеше һәм композиция характеристикалары (Ленин бакчасының өске һәм аскы террасаларын бергә тоташтыра);
- күләмле-киңлекле оешма һәм унике баскыч бүлекчәсеннән торган алты катлы кирпеч корылма структурасы;
- конструктив карар, тарихи конфигурация, корылманың геометриясе;
- фасадларның стилистикасы – конструктивизм архитектурасына якын стиль;
- архитектур карар һәм фасадларның архитектур карарлары:
  парапетлар зур күләмле кәрниз плитәләр белән томаланган. Фронталь диварларда «ПРОЛЕТАРИИ ВСЕХ СТРАН, СОЕДИНЯЙТЕСЬ!» рельефы, ул өске мәйданчыкны тышкы яктан бизи, түбәнрәк «МАРКС», «ЛЕНИН» дигән язулар. Соңгы ике катның вертикаль диварында фәнни хезмәт оешмасы эмблемасы. Ул өстән “ВРЕМЯ, сулдан вертикаль рәвештә “СИСТЕМА”, уңнан “ЭНЕРГИЯ”, астан “НОТ” дигән сүзләр белән әйләндереп алынган;
- төсләр карар – монохром төсмерләрнең нейтраль бәйләнеше;
- конструкцияләрнең материалы – кызыл керамик кирпеч; бизәкләү материалы – цемент-комлы штукатурка; декор, култыкса, койма, баскычлар материалы – мозаикалы бетон.

Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгының
2018нче елның
«________»__________
№ ___боерыгына
2- нче кушымта

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Ленин бакчасы адресы буенча урнашкан “Ленин бакчасындагы баскыч” 1924 ел, архитектор Ф.П.Гаврилов төбәк дәрәҗәсендәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләре

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Ленин бакчасы адресы буенча урнашкан “Ленин бакчасындагы баскыч” 1924 ел, архитектор Ф.П.Гаврилов төбәк дәрәҗәсендәге мәдәни мирас объекты территориясенең **картасы (схемасы)**




Мәдәни мирас объекты территориясе чикләре

Мәдәни мирас объекты

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Ленин бакчасы адресы буенча урнашкан “Ленин бакчасындагы баскыч” 1924 ел, архитектор Ф.П.Гаврилов төбәк дәрәҗәсендәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең **картографик тасвирламасы**

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Ленин бакчасы адресы буенча урнашкан “Ленин бакчасындагы баскыч” 1924 ел, архитектор Ф.П.Гаврилов төбәк дәрәҗәсендәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләре түбәндәгечә үтә:

**төньяк-көнчыгыш өлеш:** Дзержинский урамы буйлап (борылыш нокталары 2 – 3);

**көньяк-көнчыгыш өлеш:**Пушкин урамы буйлап (борылыш нокталары 3 – 4);

**көньяк-көнбатыш өлеш:** Кремль урамы, 35к1 адресы буенча урнашкан Н.И.Лобачевский исемендәге фәнни китапханә фасады буйлап (борылыш нокталары 4 – 1);

**төньяк-көнбатыш өлеш:** Лобачевский урамы 4а адресы буенча урнашкан бинаның фасады буйлап (борылыш нокталары 1 – 2).

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Ленин бакчасы адресы буенча урнашкан “Ленин бакчасындагы баскыч” 1924 ел, архитектор Ф.П.Гаврилов төбәк дәрәҗәсендәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең **борылыш нокталары таблицасы**

| Нокта № | МСК 16 та ноктаның координатлары | | 1984 елгы геодезик координаталар системасында (WGS) нокталарның координаталары | |
|---|---|---|---|---|
| | X | Y | Киңлек, B | Озынлык, L |
| 1 | 476207.6 | 1305735.25 | 55°47'35,44"N | 49°07'23,24"E |
| 2 | 476238.75 | 1305745.01 | 55°47'36,45"N | 49°07'23,81"E |
| 3 | 476229.2 | 1305775.48 | 55°47'36,14"N | 49°07'25,55"E |
| 4 | 476197.72 | 1305765.06 | 55°47'35,12"N | 49°07'24,95"E |

Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгының
2018нче елның
«________»__________
№ ___боерыгына
3 нче кушымта

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Ленин бакчасы адресы буенча урнашкан "Ленин бакчасындагы баскыч" 1924 ел, архитектор Ф.П.Гаврилов төбәк дәрәҗәсендәге мәдәни мирас объекты территориясеннән **файдалану режимы**

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Ленин бакчасы адресы буенча урнашкан "Ленин бакчасындагы баскыч" 1924 ел, архитектор Ф.П.Гаврилов төбәк дәрәҗәсендәге мәдәни мирас объекты территориясендә түбәндәге эшләр **рөхсәт ителә**:

– мәдәни мирас объектының физик яктан саклануын тәэмин итүгә юнәтелгән саклау эшләрен башкару, шул исәптән, консервацияләү, ремонтлау, реставрацияләү һәм заманча файдалануга яраклаштыру;

– мәдәни мирас объектының бөтенлегең тәэмин итү таләпләренә каршы килмәгән һәм мәдәни мирас объектының бүгенге шартларда кулланылышын тәэмин итү мөмкинлеген биргән хуҗалык эшчәнлеге алып бару;

– җир биләмәсен файдалану, мәдәни мирас объектын җир биләмәсен һәм капиталь төзелеш объектларын түбәндәге рөхсәт ителгән файдалану төрләре буенча заманча куллануга яраклаштыру (рөхсәт ителгән файдалану төрләре кодлары Россия Федерациясе икътисади үсеш министрлыгының 2014 елның 1 нче сентябрендә кабул ителгән 540 нчы номерлы "Җир биләмәләрен фадалануның рөхсәт ителгән төрләре классификаторын раслау турынлагы" боерыгы нигезендә күрсәтелгән):

гомум кулланылыштагы җир кишәрлекләре (территорияләре) (код 12.0);

– мәдәни мирас объектының югалган элементларын һәм өлешләрен гамәлдәге сызымнар, үлчәмнәр һәм тарихи аналоглар буенча реставрации юлы белән тергезү;

– башкарылучы эшләрнең (шул исәптән динамик йогынты) мәдәни мирас объектына йогынты ясамау шарты белән гамәлдәге инженер инфраструктурасы объектларын капиталь ремонтлау (тышкы суүткәргеч челтәрен, канализация, җылылык, газ һәм электр белән тәэмин итү, телефон элемтәсе белән тәэмин итү);

– территориядә мәдәни мирас объектын саклауга, файдалануга һәм популярлаштыруга юнәлтелгән төзекләндерү эшләре;

– тарихи мохит элементлары характеристикаларына җавап бирә торган аерым урнаштырылган яктырту җайланмаларын куллану;

– агачларның һәм куаклыкларның кыйммәтле токымнарын утырту; чәчәк түтәлләре һәм газоннар ясау;

- мәдәни мирас объекты фасадларын төнге яктырту җайланмаларын файдалану.

Югарыда атап үтелгән барлык эшләр мәдәни мирас объектларын саклау эшләренә мәдәни мирас объектын саклау буенча вәкаләтле орган тарафыннан бирелгән язмача рөхсәт нигезендә, мәдәни мирас объектын саклау буенча вәкаләтле орган белән килештерелгән мәдәни мирас объектларын саклап калу буенча проект документларын әзерләү һәм эшләр башкару буенча йөкләмәгә, шулай ук проект документациясенә туры китерелеп башкарыла.

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Ленин бакчасы адресы буенча урнашкан “Ленин бакчасындагы баскыч” 1924 ел, архитектор Ф.П.Гаврилов төбәк дәрәҗәсендәге мәдәни мирас объекты территориясендә түбәндәге эшләр **тыела**:

- мәдәни мирас объектын яки аның аерым элементларын, мәдәни мирас объектының тарихи-шәһәр төзелеше тирәлеген саклау белән бәйле булмаган җир казу, төзелеш, мелиоратив һәм башка эшләр башкару;
- капиталь төзелеш объектларын һәм аларның өлешләрен төзү;
- мәдәни мирас объектында, шулай ук аның территориясендә тышкы реклама чараларын урнаштыру;
- җир өстеннән инженерлык инфраструктурасы объектларын (тышкы суүткәргеч челтәрен, канализация, җылылык, газ һәм электр белән тәэмин итү, телефонлаштыру) үткәрү;
- мәдәни мирас объекты һәм аның янәшәсендәге корылмаларга динамик йөкләнеш тудыручы технологияләр файдалану;
- мәдәни мирас объекты территориясен теләсә кайсы төрдәге һәм формадагы көнкүреш калдыклары белән чүпләү;
- мәдәни мирас объектын, мәдәни мирас объектының тарихи элементларын һәм территориясен аларның җимерелү куркынычын тудыручы, мәдәни мирас объектына, шулай ук әйләнә-тирәдәге корылмаларга тискәре йогынты ясаучы куллану төрләрендә файдалану.